ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЕВЯТЕРНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДЕВӘТЕРНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2026 Девәтернә авылы № 3

2026 елга вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясен раслау турында

«Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә үз өстенә күмү бурычын алган башка затлары булган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 нчы елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә мәет җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлары булмаган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 нчы елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Э.Э. Ганиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Девәтернә авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы 3 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә үз өстенә күмү бурычын алган башка затлары булган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 нчы елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4144,72 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1017,25 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4516,66 |
| | **Барлыгы** | **9678,63** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Девәтернә авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы 3 нче
номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегендә, ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә мәет җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлары булмаган вафат булганнарны җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 нчы елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Тәнне төрү | 745,47 |
| 3. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3735,40 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 916,34 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 4281,42 |
| | **Барлыгы** | **9678,63** |